| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Бәкер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Бәкер авылында авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлегенең Бәкер авылында авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә, бирелгән вәкаләтләр нигезендә, суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;

- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны вак ташлау;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Школьная урамы, 15 нче йорт; Бакирово авылы, Нагорная урамы, 38 нче йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов